РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 13 маендагы** **Чистай шәһәре** **№ 55/8**

Чистай муниципаль районы Советы
“Чистай муниципаль районының Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы турында”
нигезләмәне раслау хакында”гы
2005 елның 28 декабрендәге 5/6 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Җир кодексының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының 2005 елның 28 декабрендәге 5/6 номерлы карары белән расланган «Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы турында»гы нигезләмәгә (Чистай муниципаль районы Советының 2005 елның 21 июлендәге 10/5 номерлы, 2015 елның 11 мартындагы 44/5 номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 5/4 номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 15/12 номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 15/5 номерлы,2019 елның 25 июлендәге 15/5 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә;

“Палата хосусый милектәге җирләрне бер категориядән (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) икенчесенә күчерү буенча вәкаләтле орган була.”;

1.2. «Палатаның төп функцияләре» 3 бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3.22 пункт өстәргә:

“3.22. Җирләрне бер категориядән (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) җир кишәрлекләре милекчеләре гаризасы буенча башка категориягә күчерүне гамәлгә ашырырга.”.

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе М.Ю. Исхаковка гамәлгә кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәве өчен тулыландырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов